КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 октябрь г.Казань № 1076

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 22 март, 233 нче, 2013 ел, 29 август, 613 нче, 2014 ел, 25 июнь, 435 нче, 2015 ел, 7 август, 577 нче, 2018 ел, 3 август, 634 нче, 2021 ел, 13 август, 718 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Пляж полосасының озынлыгына карап, пляжлар өч категориягә бүленә:

пляж полосасы озынлыгы 50 метрга кадәр булганда - өченче категория;

пляж полосасы озынлыгы 50 метрдан 150 метрга кадәр булганда - икенче категория;

пляж полосасы озынлыгы 150 метрдан артыграк булганда - беренче категория.»;

3.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Өстәлләр (калканнар) янында кимендә 2 метр биеклектәге коткаручы вышкасы билгеләнә.»;

11.3 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Коткару постында коткаручылар саны пляж категориясеннән чыгып билгеләнә:

өченче категория пляжы өчен ике коткаручы;

икенче категория пляжы өчен өч коткаручы;

беренче категория пляжы өчен 50 метр саен пляж полосасына бер коткаручы.»;

11 бүлеккә искәрмәне үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин